| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.11.2022 ел Баулы шәһәре №237

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында»гы 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарларны сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 80-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында»гы 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге 21 номерлы, 2020 елның 6 маендагы 98 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 144 номерлы, 2021 елның 9 мартындагы 33 номерлы, 2022 елның 1 сентябрендәге 179 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1 пунктта «2.17.» саннарыннан соң «2.19.» һәм «2.20» саннарын өстәргә;

Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегендә, «ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.17 статьясы. Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу нәтиҗәләрен булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү» юлыннан соң өстәргә:

| | |
|---|---|
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.19. | - Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы |

| | |
|---|---|
| статьясы<br>Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү | һәм әйдәүче белгече |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.20 статьясы<br>Составында сыекландырылган углеводород газы булган гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен товарларны балигъ булмаганнарга ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук, балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау юлы белән куллануга җәлеп итүне | - Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы һәм әйдәүче белгече |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров